**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТЕЛӘЧЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН СОВЕТЫ**
(IV чакырылыш)

утыз алтынчы утырыш
**КАРАРЫ**

11 ноябрь 2024 ел **№ 280** Теләче ав.

Теләче муниципаль район Советының 2023 елның 28 декабрендәге 228 номерлы «2024 елга муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыруның фаразлау планын (Программасын) раслау турында» карарына үзгәрешләр кертү турында

"Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында" 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, "Дәүләт һәм муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыру турында" 2001 елның 21 декабрендәге 178-ФЗ номерлы Федераль закон, "Дәүләт милкендәге яисә муниципаль милектәге һәм кече һәм урта эшкуарлык субъектлары арендалый торган күчемсез мөлкәтне читләштерү үзенчәлекләре турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында"2008 елның 22 июлендәге 159-ФЗ номерлы Федераль закон, Теләче муниципаль районы Советының 2011 елның 11 июлендәге 53 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы муниципаль мөлкәтен хосусыйлаштыру тәртибе турында нигезләмә нигезендә, МКУ «Теләче муниципаль районы Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы» ның тәкъдимен карап, Теләче муниципаль район Советы **карар итте:**

1.Теләче муниципаль район Советының 2023 елның 28 декабрендәге 228 номерлы «2024 елга муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыруның фаразлау планын (Программасын) раслау турында» карары (03.05.2024 № 243, 02.07.2024 № 253 карарлар редакциясендә) белән расланган, 2024 елда хосусыйлаштыру планлаштырылган муниципаль күчемсез мөлкәт исемлеге:

«Хосусыйлаштыру 2024 елда планлаштырыла торган муниципаль күчемсез мөлкәт исемлеге

| № т/б | Күчемсез милек объекты исеме | Урнашу урыны (адресы) | Гомуми мәйдан (кв.метр) |
|---|---|---|---|
| 1 | Җир кишәрлеге булган мәктәп бинасы | ТР, Теләче муниципаль районы, Кече Мирәтәк авылы, Пушкин ур., 11А й. | 139 |
| 2 | Җир кишәрлеге булган мәктәп бинасы | ТР, Теләче муниципаль районы, Олы Саурыш авылы, Мәктәп ур., 24 й. | 61,2 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 3 | Җир кишәрлеге булган балалар бакчасы бинасы | Татарстан Республикасы, Теләче муниципаль районы, Олы Мишә авыл җирлеге, Олы Мишә ав., Парк ур., 3 й. | 353,3 |
| 4 | Җир кишәрлеге булган балалар бакчасы бинасы | Татарстан Республикасы, Теләче муниципаль районы, Максабаш ав., Киров ур., 3А й. | 200,4 |
| 5 | Җир кишәрлеге булган Тәмте-Мәтәскә БББМ бинасы | Татарстан Республикасы, Теләче муниципаль районы, Тәмте-Мәтәскә ав., Подгорная ур., 18 й. | 84,7 |
| 6 | Җир кишәрлеге булган ясле-бакча бинасы | Татарстан Республикасы, Теләче муниципаль районы, Олы Мәтәскә ав., Фатих Хөсни ур., 37 й. | 291,2 |
| 7 | Җир кишәрлеге булган балалар бакчасы бинасы | Татарстан Республикасы, Теләче муниципаль районы, Сауш ав., Гарифуллин ур., 18 й. | 379,5». |

2. Әлеге карар гамәлдәге законнар нигезендә үз көченә керә.

Теләче муниципаль
районы Башлыгы А. Г. Фәтхуллин